РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 13 феврале № 6

**Түбән Кама шәһәр Советының «Түбән Кама шәһәр Советы депутаты статусы турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2012 елның 20 апрелендәге 17 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2018 елның 22 декабрендәге 113-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы белән, Түбән Кама шәһәре прокуратурасының 2018 елның 4 декабрендәге 02-08-01-2018 номерлы протестын игътибарга алып, Түбән Кама шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Түбән Кама шәһәр Советының «Түбән Кама шәһәр Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2012 елның 20 апрелендәге 17 номерлы карары кушымтасына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 2 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Депутат вәкаләтләре аны сайлау көненнән башлана һәм яңа чакырылыш Түбән Кама шәһәр Советы эшли башлаган көннән туктатыла.»;

1.2. 3 статьяның 1 өлешендәге 11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категорияләрдәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, кулда булган акчаны һәм кыйммәтле әйберләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) куллануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләр, тыюлар, бурычларны үтәмәү;»;

1.3. 3 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 12 пункт өстәргә:

«12) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда һәм башка федераль законнарда билгеләнгән башка очракларда.»;

1.4. 3 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Президенты депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта, вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату өчен нигез барлыкка килү көне булып, әлеге гариза Түбән Кама шәһәр Советына кергән көн санала.»;

1.5. 3 статьяның 3 өлешендә «1 өлешнең 10 һәм 11» сүзләрен «1 өлешнең 10-12» сүзләренә алмаштырырга»;

1.6. 15 статьяның 1 өлешендә «Түбән Кама шәһәре территориясендә урнашкан аларның оештыру-хокукый формасыннан бәйсез рәвештә оешмаларга һәм иҗтимагый берләшмәләргә» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.7. 15 статьяның 3 өлешендә «Түбән Кама шәһәре территориясендә урнашкан аларның оештыру-хокукый формасыннан бәйсез рәвештә оешмаларга һәм иҗтимагый берләшмәләргә» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.8. 17 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Депутат үз эшчәнлеге мәсьәләләре буенча Түбән Кама шәһәре җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары тарафыннан беренче чиратта кабул ителергә хокуклы.».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәр Советы регламенты, җирле үзидарә һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры
вазыйфаларын башкаручы,
Мэр урынбасары Э.Р. Долотказина